КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 03 май № 276

г. Казань

Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартын раслау турында

Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләре эше нәтиҗәлелеген күтәрү максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы министрлыкларының икътисадый эшчәнлек төрләре буенча министрлык ведомствосында булган оешмаларның (оештыру-хокукый формасына бәйсез) финанс-хуҗалык эшчәнлеген карап тикшерү буенча баланс комиссияләрен әзерләү һәм үткәрү стандартын (алга таба – Стандарт, баланс комиссиясе) расларга.

2. Татарстан Республикасы министрлыкларына:

өч ай эчендә үз министрлыкларының баланс комиссиясе турында нигезләмәне әлеге карар белән расланган Стандартка туры китерергә;

бер ай эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына баланс комиссиясенең эш планын тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Иминлек Советының «Татарстан Республикасында предприятиеләр һәм оешмаларның финанс эшләрен тәртипкә салу буенча эшнең торышы турында» мәсьәләсе буенча 2001 ел, 27 июль карарын үтәү чаралары хакында» 2001 ел, 05 октябрь, 732 нче карарын үз көчен югалаткан дип танырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков